Ишек артында сентябрьнен икенче яртысы. Әлегә һава жылы тора, әмма коз килеп житve сизелә. Тиздән ягу сезоны башлана. Кыш житмәсме икән, котмәгәндә?
- Юк, килмәячәк! – “Кадошкино-электротеплосеть” идарәсе директоры Р.Ш.Кильдеев, ышанычлы итеп ди. Рамиль Шамиль улы сvзләренә караганда, предприятие коллективы жәй буе жылылык һәм су трассаларын ремонтлау һәм жылыту белән шогыльләнгән. Аерым алганда, жылылык трассасынын жир асты һәм жир осте участоклары эш хәленә китерелгән: бу алыштыру да, жылыту да. Завод урамы буенча 11, 13, 15, 17 номерлы йортларга су трассасы тулысынча янартылды. Жылылык трассасынын «йорәге» - котельный участогы да игътибардан читтә калмады. Казаннар кышкы сезонга опрессовкаланган, ботен кирәкле ремонт ясалган. Су буенча да шулай. Ул тузган диярлек, шуна кvрә ремонт эшләре кон саен туктатылмый. Кайбер участок ларны тулысынча алмаштырабыз. Бу эшләр, һичшиксез, остәмә матди чыгымнар таләп итә. Шул унайдан остәп әйтәсем килә, - дип дәвам итә Р.Ш.Кильдеев,- торак-коммуналь хужа-лык коллективы финанс олеше буенча эшли. Безнен кочебез белән башкарылган эшләр кvбрәк булыр иде, ләкин бvгенге кондә халыкнын ЖКХ алдында бурычы 4,5 миллион сум тәшкил итә. Биредә жылылык буенча да, су куллану буенча да бурычлар бар. Әгәр дә вакытында предприятие хисабына акча керсә, алар кулланучыларнын vзләре очен зур файда китерер иде. Шуна кvрә, форсаттан файдаланып, безнен кулланучыларны предприятие хезмәтләре очен вакытында тvләргә чакырам.
Саранск мэриясендә узган оператив кинәшмәдә тvрәләр жылылык бирv сезонына аерым игътибар бирде. 18 сентябрьгә Саранск территориясендә 113 казылган чокырлар булуы да билгеләп vтелде. Аларнын яртысыннан артыгы «Сарансктеплотранс»нын. Анын житәкчеләре житешсезлекләрне бетервгә ике атна сораган. Мона шәһәр житәкчесе Петр Тултаев болай ди: «Когда морозы ударят, тогда булыжниками разрытия будут засыпать? Работы нужно проводить вовремя! В этом году за две недели ресурсоснабжающая организация предупреждена, что тепло в сады и школы начнет подаваться с 25 сентября, с 28 сентября- в многоквартирные дома».
Мордовия башкаласын жылыту сезонына әзерләv очен жаваплыларга бу атнада эшләрне тәмамлау турында исләренә тошерделәр.

Н.ХӘЛИЛ